МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 70 / о

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

«18» 04 2023

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау хакында» 2017 елның 01 февралендәге 17/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау турында» 2017 елның 01 февралендәге 17/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш,

архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 11 октябрендәге 180/о номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 107/о номерлы, 2019 елның 21 августындагы 106/о номерлы, 2020 елның 23 ноябрендәге 191/о номерлы, 2021 елның 25 февралендәге 30/о номерлы, 2023 елның 1 мартындагы 29/о номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва итүчеләрнең һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән, аларның граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән башка квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүдән һәм шундый бәяләү һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп кую өчен дәгъва итүчеләр арасыннан гражданинны яки граждан хезмәткәрен билгеләүдән гыйбарәт.»;

2.10 пунктта «граждан хезмәте, әмма» сүзләреннән соң «һөнәри дәрәҗә,» сүзләрен өстәргә;

4.1 пунктта «бәяләү методларында» сүзләреннән соң «һөнәри дәрәҗәдәге,» сүзләрен өстәргә;

4.2 пунктта «бәяләү методларында» сүзләреннән соң «һөнәри дәрәҗәдәге,» сүзләрен өстәргә;

4.9 пунктның уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданинның (граждан хезмәткәренең) һөнәри белем дәрәҗәсенә, граждан хезмәте стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше, һөнәри дәрәҗәгә квалификация таләпләренә, шулай ук, министрның тиешле карары булганда – вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле, өстәмә яңадан һөнәри әзерлек үзләштерү нәтиҗәләре буенча белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (эреләндерелгән белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре төркемнәренә карата), квалификациягә карата таләпләргә туры килүен тикшерү.»;

4.16 пунктның өченче абзацында «конкурс комиссиясе» сүзләреннән соң «һөнәри дәрәҗәдәге,» сүзләрен өстәргә;

4.17 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.17. Конкурс уздырылганда конкурс комиссиясе кандидатларны алар тарафыннан тапшырылган белеме һәм (яки) квалификациясе, граждан хезмәтен яки бүтән дәүләт граждан хезмәтен үтүе, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруы турындагы документлар нигезендә, шулай ук тест уздыру һәм

кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләү буенча федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган һөнәри дәрәҗәдәге бәяләү методларын кулланып, бүтән конкурс процедуралары нигезендә, шул исәптән тест уздыру, структур бүлекчә эшчәнлеге юнәлеше буенча кандидат тарафыннан документ проектын әзерләү һәм кандидатлар Министрлыкта аны биләү өчен дәгъва белдергән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләрдә шәхси әңгәмә уздыру юлы белән бәяли. Бу вакытта кандидат белән тест һәм индивидуаль әңгәмә уздыру барлык кандидатлар өчен дә мәҗбүри методлар булып тора.»;

4.21 пунктның өченче абзацында «комиссия бәяли» сүзләреннән соң «һөнәри дәрәҗә,» сүзләрен өстәргә;

4,28 пунктта «граждан хезмәте вазыйфалары» сүзләреннән соң «һөнәри дәрәҗә,» сүзләрен өстәргә;

Күрсәтелгән Нигезләмәгә 2 нче кушымтаның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен гражданинның (граждан хезмәткәренең) һөнәри белем дәрәҗәсенә, граждан хезмәте стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше, һөнәри дәрәҗәгә карата квалификация таләпләренә, шулай ук, министрның тиешле карары булганда – вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле, өстәмә яңадан һөнәри әзерлек үзләштерү нәтиҗәләре буенча белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (эреләндерелгән белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре төркемнәренә карата), квалификациягә карата таләпләргә туры килүе таләп ителә.»;

3 нче кушымтаның 4 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Белем һәм (яки) квалификация турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданинның теләге буенча хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турындагы документлар күчермәләре;»;

әлеге Нигезләмәнең 5 нче кушымтасы атамасында «Бәяләү методлары» сүзләреннән соң «һөнәри дәрәҗәдәге,» сүзләрен өстәргә.

2. Юридик бүлек җитәкчесе (Э.Ю.Латыйповага) дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Җ.Зәйнуллинага) әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура

һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык 2023 елның 29 апреленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М.Айзатуллин

Отдел контроля исполнения документов